# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

унберенче утырыш

**КАРАРЫ**

30 нчы июнь 2021 ел **№ 61** Теләче авылы

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр тапшыру һәм Теләче муниципаль районы Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 17 маендагы 10/13-09/2400 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Указын үтәү йөзеннән, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Теләче муниципаль район Советының 2019 елның 16 декабрендәге 217 номерлы карары (2021 елның 30 мартындагы 47 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә, 5 пунктның «3» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), хисап чорында цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә.

2. Теләче муниципаль район Советының 2014 елның 7 ноябрендәге 229 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә, 6 пунктының «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), хисап чорында цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-биреш буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә.»;

3. Теләче муниципаль районы Советының 2017 елның 19 июлендәге 92 номерлы карары белән расланган Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» челтәрендә Теләче муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында Нигезләмәгә, 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) уртак кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

4. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль район Советының законлылык, хоку тәртибен һәм депутат этикасын тәэмин итү буенча булган комитетына йөкләргә.

Теләче муниципаль
районы Башлыгы — Н.Н. Хаҗипов